РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА
Чалпинского сельского поселения
Азнакаевского
муниципального района

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Азнакай
муниципаль районы Чалпы авыл жирлеге
Советы
БАШЛЫГЫ

ул. Центральная, д.35, с. Чалпы, 423324
Азнакаевского муниципального района
Тел. (8-5592) 35-5-46, факс (8-5592) 35-5-46
Chal.Azn@tatar.ru

Узэк урамы, 35, Чалпы авылы, 423324
Тел. (8-5592) 35-5-46,
факс (8-5592) 35-5-46
Chal.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«01» ноябрь 2019 ел № 3

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге Ирекле торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге Уставы белән, **карар чыгарам:**

1. 11.11.2019 ел Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге Ирекле торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

1.2. Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге Ирекле торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы-Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге Башкарма комитеты;
- гражданнар җыенын үткәрү вакыты – 11 ноябрь 2019 ел 13.00 сәг.тән 14.00 сәг.кадәр;
- үткәрү урыны – Ирекле авылы, Гагарина ур. , 42 йорт, Ирекле авыл мәдәният йорты залы ;

1.3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2019 елның 5 ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Чалпы авылы, Үзәк урамы, 35 йорт;
- сайлау хокукына ия булган Ирекле торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;
- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;
- Ирекле торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм гражданнар җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итәргә;

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 Чалпы авыл җирлеге Ирекле торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Ирекле авылында Гагарин урамына, Наратлы урамына вак таш җәелгән юлларның чокырларын ремонтлау (сатып алу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү);
- Ирекле авылында урамнарны яктырту, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, энергия саклаучы лампалар урнаштыру, килешү буенча эш өчен түләү;
- Ирекле авылы территориясендә көнкүреш калдыкларын һәм чүп-чарны вакытлыча җыю территорияләрен җыештыру, чистарту;
- Ирекле авылы зиратлары өчен җиһазлар һәм инвентарь сатып алу;
- Ирекле авылында янгын сүндергечләр, янгын ранецлары, янгын сүндерү инвентаре сатып алу;
- Ирекле авылында юлларны кардан чистарту;
- Ирекле авылында җәйге чорда территорияне чабу;
- Ирекле авылында коры агач, куаклар кисү, чабу;
- Ирекле авылында су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (материал, җиһазлар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, торбаларны алыштыру, килешү буенча эш өчен түләү);
- Ирекле авылында һәлак булган сугышчыларга куелган һәйкәлләрне ремонтлау (коймалар урнаштыру, буяу, агарту, эшләр өчен килешү буенча түләү) ;
- Ирекле авылында урам исемнәре язылган табличкалар ясау;
- Ирекле авылында гидротехник корылмаларда «су коенырга ярамый» дигән табличкалар ясау, урнаштыру;
-Ирекле авылында бәйрәм чараларын («Яңа ел», «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне») оештыру һәм үткәрү.

« РИЗА» «КАРШЫ»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Чалпы авылы, Ленина ур., 130 йорт, Үзәк ур., 39 йорт, Чалпы авылы мәктәп бинасында, амбулатория бинасында урнашкан мәгълүмат стендларында, Камышлы, Ирекле, Балан-Бүләк авыллары мәгълүмат стендларында урнаштырырга.
3. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымнан калдырам.

Башлык: А.М. Мөхәмәтшин